| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**Карар** **Решение**

№ 5-8 от «01» июль, 2016 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2014 елның 18 ноябрендәге№ 7-34 карары белән расланган Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

“Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-988 номерлы Указы, Указом Президента Республики Татарстан 13 октября 2015 года N УП-988), “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2014 елның 18 ноябрендәге № 7-34 карары белән расланган Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

Нигезләмәнең 6 пунктындагы "в" пунктчасында һәм 13 пунктында "акцияләр" сүзен төшереп калдырырга.

2. Карарны Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район Советы рәисе А.П. Иванов